| СОВЕТ РОМОДАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ РОМОДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

с. Ромодан

20.06.2019 № 91

**Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Ромодан авыл җирлеге Советының
Татарстан Республикасы Алексеевск
муниципаль районы
Ромодан авыл җирлеге составына
керә торган торак пунктларда
гражданнар җыеннары үткәрүгә
әзерлек тәртибе турында 2018 елның
21 сентябрь 67 санлы карарын
раслау турында нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү турында**

Гамәлдәге законнарга, шул исәптән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында " 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 13 пунктындагы 4 нче абзацка да туры китереп»

**Ромодан авыл җирлеге Советы карар итә:**

**1**.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 сентябрь 67 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ромодан авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Авыллар арасындагы территорияләрдә урнашкан торак пунктларда, яңа төзелгән җирлек булдыру турында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр дә аның сайлау хокукына ия кешеләре саны 300 дән артык кеше булмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5 Гражданнар җыены сайлау хокукына ия торак пункт халкының яртысыннан артыгы катнашса узарга хокуклы. Әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта сайлау хокукына ия булган, составына әлеге торак пункт керә торган муниципаль берәмлек

уставы нигезендә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгәннән соң бер айдан артмаган вакытка этаплап үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмый».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, җирлек сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ромодан авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3 Карарның үтәлешен үзем контрольдә тотачакмын.

**Алексеевск**
**муниципаль районының**
**Ромодан авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.А. Чекалина**